| | | |
|---|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«10» 03 2021 ел Болгар ш. № 174

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 25 декабрендәге 715 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыру турында нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

Россия Федерациясе гражданнарын мәктәпкәчә белем бирүнең мәгариф программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда «Мәктәпкәчә белем бирүнең мәгариф программалары буенча белем алу тәртибен раслау турында» Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2020 елның 15 маендагы 236 номерлы боерыгы белән расланган яңа кагыйдәләр үтәүне тәэмин итүгә бәйле рәвештә, Спас муниципаль районының башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 25 декабрендәге 715 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыру турында нигезләмәгә түбәндәге өстәмәләр һәм үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1 бүлекнең 1.1 пунктында «Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы тарафыннан расланган 08.04.2014 № 293» сүзләрен «Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы тарафыннан расланган 2020 елның 15 маендагы 236 номерлы» сүзләренә алмаштырырга.

1.2. 2 бүлекнең 2.4 пунктында «Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2014 елның 8 апрелендәге 293 номерлы раслаган» сүзләрен «Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2014 елның 15 маендагы 236 номерлы раслаган» сүзләренә алмаштырырга.

1.3. 2.19 пунктында «күрсәтелгән» сүзеннән соң « белешмәләр һәм » сүзләрен өстәргә;

1.4. 2 бүлекнең 2.19 пунктында «2014 елның 8 апрелендәге 293 номерлы» сүзләрен «2020 елның 15 маендагы 236 номерлы» сүзләренә алмаштырырга;

1.5. 2 бүлекнең 2.21 пунктында «14, 15, 16 пунктлары нигезендә» сүзләрен «9 пункт нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

1.6. 2 бүлекнең 2.21 пунктында «2014 елның 8 апрелендәге 293 номерлы» сүзләрен «2020 елның 15 маендагы 236 номерлы» сүзләренә алмаштырырга.

1.7. 2 бүлекнең 2.24. пунктына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы тарафыннан расланган 2020 елның 15 маендагы 236 номерлы мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча укыту Тәртибенең 12 пункты».

1.8. 4 бүлекнең 4.6 пунктында «2014 елның 8 апрелендәге 293 номерлы» сүзләрен «2020 елның 15 маендагы 236 номерлы» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Спас муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Е.В. Савиновка йөкләргә.

ТР Спас муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе В.А. Осокин